**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О Совете при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке

В целях содействия развитию науки и образования в Республике Татарстан, а также совершенствования государственного управления в этой сфере **постановляю:**

1. Создать Совет при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке.

2. Утвердить:

Положение о Совете при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке (приложение № 1);

состав Совета при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
07 февраля 2015 года
№ УП-105

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «07» февраля 2015 года

№ УП - 105

**Положение**
**о Совете при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке**

1. Совет при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке (далее – Совет) является совещательным органом при Президенте Республики Татарстан, созданным в целях обеспечения взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, работодателей, образовательных и научных организаций, общественных объединений при рассмотрении вопросов, связанных с развитием образования и науки, а также в целях выработки предложений Президенту Республики Татарстан по актуальным вопросам государственной политики в области образования и научно-технического развития.

2. Совет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

3. Положение о Совете и его состав утверждаются указом Президента Республики Татарстан.

4. Основными задачами Совета являются:

а) подготовка предложений Президенту Республики Татарстан по приоритетным направлениям и механизмам развития образования и науки в Республике Татарстан;

б) координация деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, образовательных и научных организаций, государственных фондов поддержки научной, научно-технической и инновационной деятельности, общественных объединений в области развития образования и науки.

5. Совет для решения возложенных на него основных задач имеет право:

а) запрашивать и получать в установленном порядке необходимые материалы от органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, предприятий и организаций, общественных объединений, образовательных, научных и иных организаций,

а также от должностных лиц;

б) приглашать на свои заседания и заслушивать на них должностных лиц органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, представителей общественных объединений, образовательных, научных и иных организаций;

в) направлять членов Совета и своих представителей для участия в совещаниях, конференциях и семинарах, проводимых федеральными органами государственной власти, органами государственной власти Республики Татарстан и других субъектов Российской Федерации, органами местного самоуправления, общественными объединениями, образовательными, научными и иными организациями по актуальным вопросам, относящимся к сфере образования и науки;

г) привлекать в установленном порядке для осуществления информационно-аналитических и экспертных работ образовательные, научные и иные организации, а также ученых и специалистов, в том числе на договорной основе;

д) пользоваться в установленном порядке базами данных Аппарата Президента Республики Татарстан, Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, органов исполнительной власти Республики Татарстан.

6. Совет формируется в составе председателя Совета, его заместителей, секретаря и членов Совета. Члены Совета принимают участие в его работе на общественных началах.

Председателем Совета является Президент Республики Татарстан.

7. Совет в соответствии с возложенными на него основными задачами создает из числа своих членов, а также из числа не входящих в состав Совета ведущих российских ученых, представителей органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления и общественных организаций межведомственные рабочие группы по перспективным направлениям развития науки и образования.

8. Руководители межведомственных рабочих групп утверждаются Президентом Республики Татарстан.

9. Решением Совета могут создаваться временные рабочие группы, подгруппы, советы и экспертные комиссии для подготовки предложений по отдельным вопросам, связанным с решением возложенных на Совет задач.

10. Подготовку и организацию проведения заседаний Совета, контроль за исполнением его решений, а также решение текущих вопросов деятельности Совета осуществляет секретарь Совета.

11. Заседания Совета проводятся не реже одного раза в шесть месяцев. В случае необходимости могут проводиться внеочередные заседания Совета.

12. Заседание Совета ведет председатель Совета либо по его поручению один из заместителей председателя Совета.

13. Заседание Совета считается правомочным, если на нем присутствует не менее половины членов Совета.

14. Решения Совета принимаются большинством голосов присутствующих на заседании членов Совета. Решения Совета оформляются протоколом, который подписывает председатель Совета. Для реализации решений Совета могут издаваться указы и распоряжения Президента Республики Татарстан.

15. Решения Совета направляются в Кабинет Министров Республики Татарстан, Государственный Совет Республики Татарстан, органы государственной власти Республики Татарстан, а также ответственным исполнителям.

16. Организационно-техническое обеспечение деятельности Совета осуществляет Аппарат Кабинета Министров Республики Татарстан.

17. Расходы, связанные с обеспечением деятельности Совета, в том числе расходы на проезд и проживание иногородних членов Совета, прибывших для участия в его заседании, членов создаваемых Советом межведомственных рабочих групп, временных рабочих групп, подгрупп, советов, экспертных комиссий и лиц, привлекаемых для осуществления информационно-аналитических и экспертных работ, осуществляются за счет бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на обеспечение деятельности Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «07» февраля 2015 года

№ УП - 105

**Состав**
**Совета при Президенте Республики Татарстан по образованию и науке**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Совета |
| Гафуров Ильшат Рафкатович | ректор Казанского (Приволжского) федерального университета, заместитель председателя Совета (по согласованию) |
| Салахов Мякзюм Халимулович | президент Академии наук Республики Татарстан, заместитель председателя Совета (по согласованию) |
| Синяшин Олег Герольдович | председатель Казанского научного центра Российской академии наук, заместитель председателя Совета (по согласованию) |
| Фаттахов Энгель Навапович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан, заместитель председателя Совета |
| Поминов Андрей Иванович | первый заместитель министра образования и науки Республики Татарстан, секретарь Совета |
| Баклашова Ольга Николаевна | директор Гимназии № 6 Приволжского района города Казани (по согласованию) |
| Гильмутдинов Альберт Харисович | ректор Казанского национального исследовательского технического университета им. А.Н. Туполева-КАИ (по согласованию) |
| Говорун Вадим Маркович | заместитель директора по научной работе Научно-исследовательского института физико-химической медицины Федерального медико- |

| | |
|---|---|
| | биологического агентства (по согласованию) |
| Дьяконов Герман Сергеевич | ректор Казанского национального исследовательского технологического университета (по согласованию) |
| Иванов Владимир Петрович | генеральный директор ОАО «Научно-производственное объединение «Государственный институт прикладной оптики» (по согласованию) |
| Каблов Евгений Николаевич | генеральный директор Всероссийского научно-исследовательского института авиационных материалов (по согласованию) |
| Клименко Александр Викторович | председатель Экспертного совета по научным проектам Российского научного фонда (по согласованию) |
| Когогин Сергей Анатольевич | генеральный директор ОАО «КАМАЗ» (по согласованию) |
| Лунин Валерий Васильевич | декан химического факультета Московского государственного университета им. М.В. Ломоносова (по согласованию) |
| Маганов Наиль Ульфатович | генеральный директор ОАО «Татнефть» (по согласованию) |
| Некипелов Александр Дмитриевич | директор Московской школы экономики Московского государственного университета им. М.В. Ломоносова (по согласованию) |
| Нургалиев Данис Карлович | проректор по научной деятельности Казанского (Приволжского) федерального университета (по согласованию) |
| Сагдеев Ренад Зиннурович | директор Института «Международный томографический центр» Сибирского отделения Российской академии наук (по согласованию) |
| Фрумин Исак Давидович | научный руководитель Национального исследовательского университета «Высшая школа экономики» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Хабриева Талия Ярулловна | директор Института законодательства и сравнительного правоведения при Правительстве Российской Федерации (по согласованию) |
| Хайруллин Айрат Ринатович | помощник Президента Республики Татарстан |
| Хасанов Рустем Шамильевич | главный врач Республиканского клинического онкологического диспансера (по согласованию) |
| Шадриков Владимир Дмитриевич | действительный член Российской академии образования (по согласованию) |
| Яруллин Рафинат Саматович | генеральный директор ОАО «Татнефтехиминвест-холдинг» |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы турында

Татарстан Республикасында фән һәм мәгарифне үстерүгә булышлык итү, шулай ук әлеге өлкәдә дәүләт идарәсен камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советын оештырырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы составын (2 нче кушымта).

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 07 февраль
№ ПУ-105

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «_07_»февралендәге
ПУ-_105_ номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы**
**Мәгариф һәм фән советы турында**
**нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, эш бирүчеләр, мәгариф һәм фәнни оешмалар, җәмәгать берләшмәләренең мәгариф һәм фән үсеше белән бәйле мәсьәләләрне караганда үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, шулай ук мәгариф һәм фәнни-техник үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтенең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү максатларында оештырылган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы киңәшмә органы булып тора.

2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

3. Совет турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә раслана.

4. Советның төп бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

а) Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасында мәгариф һәм фән үсешенең өстенлекле юнәлешләре һәм механизмнары буенча тәкъдимнәр әзерләү;

б) мәгариф һәм фән үсеше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф һәм фәнни оешмалар, фән, фәнни-техник һәм инновация эшчәнлегенә булышлык итү дәүләт фондлары, җәмәгать оешмалары эшчәнлеген координацияләү.

5. Совет үзенә йөкләнгән төп бурычларны хәл итүдә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, предприятиеләрдән һәм оешмалардан, җәмәгать оешмаларыннан, мәгариф, фәнни һәм башка оешмалардан, шулай ук

вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материалларны соратып алырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларын, җәмәгать оешмалары, мәгариф, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен үзләренең утырышларына чакырырга һәм аларның чыгышларын тыңларга;

в) Совет әгъзаларын һәм үзләренең вәкилләрен федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясенең башка субъектлары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, мәгариф, фәнни һәм башка оешмалар тарафыннан уздырылучы мәгариф һәм фән өлкәсенең актуаль мәсьәләләренә кагылышлы киңәшмәләр, конференцияләр һәм семинарларда катнашу өчен җибәрергә;

г) мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен башкаручы өчен билгеләнгән тәртиптә мәгариф, фәнни һәм башка оешмаларны, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне, шул исәптән шартнамәләр төзү юлы белән дә, җәлеп итәргә;

д) билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белешмәләр базасыннан файдаланырга.

6. Советның составы Совет рәисе, аның урынбасарлары, секретаре һәм Совет әгъзаларыннан төзелә. Совет әгъзалары аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

Совет рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

7. Совет үзенә йөкләнгән төп бурычлар нигезендә үзенең әгъзаларыннан, шулай ук Совет составына кермәүче илебезнең әйдәп баручы галимнәреннән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм җәмәгать оешмалары вәкилләреннән торган фән һәм мәгариф үсешенең перспективалы юнәлешләре буенча ведомствоара эш төркемнәре оештыра.

8. Ведомствоара эш төркемнәре җитәкчеләре Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

9. Совет карары нигезендә Советка йөкләнгән аерым бурычларны хәл итү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен вакытлы эш төркемнәре, төркемчәләр, советлар һәм эксперт комиссияләре оештырылырга мөмкин.

10. Совет утырышларын уздыруны әзерләү һәм оештыруны, аның карарларының үтәлешен контрольдә тотуны, шулай ук Совет эшчәнлегенең агымдагы мәсьәләләрен хәл итүне Совет секретаре тормышка ашыра.

11. Совет утырышлары кимендә алты айга бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта, Советның чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

12. Совет утырышын Совет рәисе яисә аның кушуы буенча Совет рәисе урынбасарларының берсе алып бара.

13. Совет утырышы, әгәр дә анда Совет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

14. Совет карарлары утырышта катнашучы Совет әгъзаларының күпчелек тавыш бирүе нигезендә кабул ителә. Совет карарлары Совет рәисе кул куючы беркетмә белән рәсмиләштерелә. Совет карарларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары чыгарылырга мөмкин.

15. Совет карарлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, шулай ук җаваплы затларга җибәрелә.

16. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тәэмин итә.

17. Совет эшчәнлеген тәэмин итү, шул исәптән Совет утырышларында катнашу өчен башка шәһәрләрдән килүче әгъзаларының юл чыгымнарын һәм торак чыгымнарын, Совет тарафыннан оештырылучы ведомствоара эш төркемнәре, вакытлыча эш төркемнәре, төркемчәләр, советлар һәм эксперт комиссияләре әгъзалары һәм мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен башкару өчен җәлеп ителүче затларга тотылган чыгымнар Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты эшчәнлеген тәэмин итүгә каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән тормышка ашырыла.

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «07» февралендәге
ПУ-105 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы**
**Мәгариф һәм фән советы**
**составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Совет рәисе |
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлахов<br>Мәкъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Синяшин<br>Олег Герольдович | Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Фәттахов<br>Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Поминов<br>Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, Совет секретаре |
| Баклашова<br>Ольга Николаевна | Казан шәһәре Идел буе районының 6 номерлы гимназиясе директоры (килешү буенча) |
| Гыйльметдинов<br>Альберт Харис улы | А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ ректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Говорун Вадим Маркович | Федераль медицина-биология агентлыгының Физика-химия медицинасы фәнни-тикшеренү институты директорының фәнни эш буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Дьяконов Герман Сергеевич | Казан милли тикшеренү технология университеты ректоры (килешү буенча) |
| Иванов Владимир Петрович | «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Каблов Евгений Николаевич | Бөтенроссия авиация материаллары фәнни-тикшеренү институты генераль директоры (килешү буенча) |
| Клименко Александр Викторович | Россия фәнни фондының Фәнни проектлар буенча эксперт советы рәисе (килешү буенча) |
| Когогин Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Лунин Валерий Васильевич | М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының химия факультеты деканы (килешү буенча) |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Некипелов Александр Дмитриевич | М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Мәскәү икътисад мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Нургалиев Данис Карл улы | Казан (Идел буе) федераль университетының фәнни эшчәнлек буенча проректоры (килешү буенча) |
| Сәгъдиев Ренат Зиннур улы | Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге «Халыкара томография үзәге» институты директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фрумин<br>Исак Давидович | «Икътисад югары мәктәбе» Милли тикшеренү университеты фәнни җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хәбриева<br>Талия Ярулла кызы | Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Законнар чыгару һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры (килешү буенча) |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Хәсәнов<br>Рөстәм Шамил улы | Республика клиник онкология диспансеры баш табибы (килешү буенча) |
| Шадриков<br>Владимир Дмитриевич | Россия мәгариф академиясе хакыйкый әгъзасы (килешү буенча) |
| Яруллин<br>Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры |

---